РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

---

24 июль 2023 ел №191

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында»2021 елның 30 сентябрендәге № 63 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 17 мартындагы 71 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге № 63 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктында:

- «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң беренче абзацта «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар» сүзтезмәсе белән тулыландырырга.

- түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга: «12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр».

1.2. 1.6 пунктның беренче, икенче, өченче абзацларында «1-11» саннарын «1-12» саннары белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов